“Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Урта Курса авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге составына керүче Сарай-Чокырча тимер юл разъезды бетерү мәсьәләсе буенча фикер алышу буенча гавами тыңлаулар

БЕРКЕТМӘСЕ

7 ноябрь 2025 ел

Үткәрү вакыты: 7 ноябрь 2025 ел

Үткәрүне башлау вакыты: 15.00 сәгать

Үткәрү тәмамлану вакыты: 15.30 сәгать

Үткәрү срогы - 1 көн

Үткәрү урыны: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Арча районы, Урта Курса авылы, Яшьләр ур., 13 йорт (Урта Курса мәдәният йорты бинасы).

Гавами тыңлаулар уздыру өчен нигез: "Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль Законның 47 маддәсе, Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Советының 2025 елның 13 августындагы “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Урта Курса авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге составына керүче Сарай-Чокырча тимер юл разъезды бетерү мәсьәләсе буенча фикер алышу буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында” 6 номерлы карары.

Гавами тыңлаулар инициаторы: Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Курса авыл җирлеге Советы.

Гавами тыңлауларда каралган мәсьәләнең исеме: “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Урта Курса авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге составына керүче Сарай-Чокырча тимер юл разъезды бетерү.

Халыкка гавами тыңлаулар турында мәгълүмат бирү: гавами тыңлаулар уздыру турында мәгълүмати белдерү (Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Советының 2025 елның 21 октябрьнен 6 номерлы карары):

- Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында;
- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында;
- Урта Курса авыл җирлеге территориясендә түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: ТР, Арча районы, Урта Курса авылы, Тукай урамы, 21 йорт, ТР, Арча районы, Югары Курса авылы, Мәктәп урамы, 16а йорт, ТР, Арча районы, Түбән Курса авылы, Мәскәү урамы, 30а йорт, ТР, Арча районы, Алан авылы, Һ. Такташ урамы, 23 йорт каршында, ТР, Арча районы, Сарай-Чокырча авылы, Б. Красная урамы, 21 йорт, ТР, Арча районы, Корайван авылы, М.Гафури урамы, 9 йорт.

**Көн тәртибе:**

*“Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Урта Курса авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге составына керүче Сарай-Чокырча тимер юл разъезды бетерү турында”.*

Гавами тыңлауларда катнашучыларның тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен кабул итү вакыты турында мәгълүмат: 2025 елның 22 октябереннан 6 ноябренэ кадәр.

Рәислек итүче: Татарстан Республикасы Арча районының Урта Курса авыл җирлеге башлыгы - Вафина Рәмзия Рамазан кызы.

сәркатип: Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Курса авыл җирлеге башкарма комитеты сәркатибе - Шакирова Әлфия Марсель кызы

Катнаштылар:

Арча муниципаль районының Урта Курса авыл җирлегендә яшәүче 23 кеше.

Тавыш бирү формасы: кул күтәрү юлы белән ачык тавыш бирү.

Гавами тыңлаулар башланганчы гавами тыңлауларга чыгарылган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, шулай ук гавами тыңлауларда катнашучыларның чыгышларына гаризалар килмәде.

Тыңладылар:

Хамзина А.Ф. — гавами тыңлауларда катнашучыларны көн тәртибе һәм гавами тыңлауларны үткәрү тәртибе белән таныштырды, гавами тыңлауларда катнашучыларга торак пунктны бетерү өчен хокукый нигез булып Россия Федерациясе Конституциясе нигезләмәләре, Арча муниципаль районының Урта Курса авыл җирлеге Уставы торуын аңлатты.

Бетерү сәбәпләре:

Арча муниципаль районының Урта Курса авыл җирлеге составына 2025 елның 1 маена 7 торак пункт керә: 220 кеше яшәгән Урта Курса авылы, 195 кеше яшәгән Түбән Курса авылы, 192 кеше яшәгән Югары Курса авылы, 124 кеше яшәгән Алан авылы, 246 кеше яшәгән Сарай-Чокырча авылы, 66 кеше яшәгән Корайван авылы, Сарай-Чокырча тимер юл разъездында – 0 кеше.

Сарай-Чокырча тимер юл разъезды “Сеҗе-Арча” региональ әһәмияттәге юлыннан якынча 3500 м ераклыкта урнашкан. Планлаштырылган торак пункт урынында Сарай-Чокырча тимер юл разъезы урнашкан, кадастр карталары буенча, җирдә түбәндәге категориягә керә торган тимер юл урнашкан: сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшырулар, телевидение, информатика җирләре, космик эшчәнлекне тәэмин итү өчен җирләр, оборона, иминлек җирләре һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр. Бу территориядә торак пунктларның җирләре юк.

Территориядә электр тапшыру линияләренең терәкләре, үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү, су агызу, газ белән тәэмин итү юк, Урта Курса авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге юллар категориясенә кертелгән Түбән Курса торак пунктына кадәр юл бар. Әлеге җир кишәрлеге территориясендә социаль объектлар, истәлекле урыннар юк. Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге мәгълүматлары буенча, торак пунктта теркәлгән кешеләр юк.

Урта Курса авыл җирлегенең Сарай Чокырча тимер юл разъезды буенча 2002-2006 еллар чорына салынган 6 нчы хуҗалык кенәгәсе буенча, 3 йорт

хуҗалыгы алып бару турында язмалар гамәлгә ашырылган. Шулай ук югарыда күрсәтелгән 3 нче хуҗалык китабы мәгълүматларына караганда, барлык әгъзалар 2006 елга кадәр үлү сәбәпле йорт хуҗалыкларыннан китკәннәр. Урта Курса авыл җирлегенең 2007 елдан алып бүгенге көнгә кадәрге чорда нигез салынган хуҗалык кенәгәләрендә Сарай-Чокырча тимер юл разъезды буенча йорт хуҗалыклары алып бару турында яңа язмалар кертелмәгән.

Югарыда әйтелгәннәрне исәпкә алып, Сарай-Чокырча тимер юл разъезды торак пункт билгеләрен югалтуын, фактта эшләмәвен һәм алга таба үсеш перспективалары булмавын билгеләп үтәргә кирәк.

Гавами тыңлаулар барышында Урта Курса авыл җирлегендә яшәүчеләрдән "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Урта Курса авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге составына керүче Сарай-Чокырча тимер юл разъезды бетерүгә кагылышлы сораулар килмәде.

Рәислек итүче гавами тыңлауларда катнашучыларга "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Курса авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге составына керүче Сарай-Чокырча тимер юл разъезды бетерүне хупларга тәкъдим итте.

Тавыш бирделәр: «уңай» — 23 , «каршы» - 0, «тыелып калдылар» — 0.

Карар кылдылар:

1. "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Урта Курса авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге составына керүче Сарай-Чокырча тимер юл разъезды бетерүне хупларга.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Курса авыл җирлеге Советына "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Курса авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге составына керүче Сарай-Чокырча тимер юл разъезды бетерүгә халыкның ризалыгын белдерергә тәкъдим итәргә.

Рәис Вафина Р.Р.

Сәркатип Шакирова А.М.